МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.09.2023 Казан ш. № 21-53-280

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Татарстан Республикасы алдындагы алдында акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны исәптән чыгару һәм юкка чыгару һәм торгызу кагыйдәләре (нигезләре, шартлары һәм тәртибе) билгеләү турында» 2019 елның 17 октябрендәге 21-53-244 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны исәптән чыгару һәм юкка чыгару һәм торгызу кагыйдәләренә (нигезләре, шартлары һәм тәртибе) үзгәрешләр кертү турында

Б о е р ы к б и р ә м:

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Татарстан Республикасы алдындагы алдында акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны исәптән чыгару һәм юкка чыгару һәм торгызу кагыйдәләрен (нигезләре, шартлары һәм тәртибе) билгеләү турында» 2019 елның 17 октябрендәге 21-53-244 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны исәптән чыгару һәм юкка чыгару һәм торгызу кагыйдәләренә (нигезләре, шартлары һәм тәртибе) кертелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
18.09.2023 ел № 21-53-280
боерыгы белән расланды

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Татарстан Республикасы алдындагы алдында акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны исәптән чыгару һәм юкка чыгару һәм торгызу кагыйдәләрен (нигезләре, шартлары һәм тәртибе) билгеләү турында» 2019 елның 17 октябрендәге 21-53-244 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны исәптән чыгару һәм юкка чыгару һәм торгызу кагыйдәләренә (нигезләре, шартлары һәм тәртибе) кертелгән үзгәрешләр

1. 2.2 пунктта:

1) түбәндәге эчтәлекле 2.2.2[1] пунктча өстәргә:

«2.2.2[1]. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, индивидуаль эшкуар булмаган гражданның – бурычлы, банкрот дип тануы.»;

2) 2.2.5 пунктчасында «3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләрдә» сүзләрен «3 яисә 4 пунктларында каралган нигезгә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 2.2.6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.6. «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында яисә 4 пунктында каралган очракларда башкарма документның түләтүчесенә кире кайтуга бәйле рәвештә башкарма эшне башкару тәмамланган дип элек суд приставы тарафыннан чыгарылган карар нигезендә юридик затны – бурычлыны бердәм дәүләт реестрыннан теркәү органы карары буенча төшереп калдырулары».

2. Түбәндәге эчтәлекле 3.2[1] пункт белән тулыландырырга:

«3.2[1]. Әлеге Кагыйдәләрнең 2.2 пунктының 2.2.2[1] пунктчасында күрсәтелгән очракта бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы карар түбәндәгеләр нигезендә кабул ителә:

а) өземтәләр;

б) белешмәләр;

в) индивидуаль эшкуар булмаган гражданинны банкрот дип тану турында суд карары күчермәсе яисә индивидуаль эшкуар булмаган гражданны банкрот дип тану турында Бердәм федераль реестрдан судтан тыш тәртиптә мәгълүмат.».

3. 3.5 пунктындагы «в» пунктчасында «3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләрдә» сүзләрен «3 яисә 4 пунктларында каралган нигездә» сүзләренә алмаштырырга.

4. 4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Татарстан Республикасы алдындагы алдында акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны исәптән чыгаруны оештыру максатларында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән Активларның керүе һәм чыгуы буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы комиссиясе (алга таба - Комиссия) төзелә.

Комиссия, Комиссия рәисен дә кертеп, биш әгъза составында төзелә. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия.

Комиссия эше белән Комиссия рәисе яисә аның вазыйфаларын башкаручы зат җитәкчелек итә. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, тулы хокуклы булып санала.».

5. 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Кайтарып бирелә торган (кире кайтарып бирелә торган) нигездә акчалар Татарстан Республикасы тарафыннан бирелүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән бурычка карата Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының анализ һәм стратегия бүлеге яисә дәүләт гарантиясен бирүгә һәм (яисә) үтәүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән бурычка карата Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бюджет сәясәте бүлеге бурычны түләтүне өметсез дип тануга нигезләрне раслый торган документлар пакетын әлеге Кагыйдәләрнең III бүлеге нигезендә әзерли һәм Комиссиягә юллый.

Комиссия документларның тәкъдим ителгән пакетын килгән көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә карый. Комиссия утырышын үткәрү датасын, вакытын һәм урынын аның рәисе яисә рәис вазыйфаларын башкаручы зат билгели. Комиссиянең һәр акчалата йөкләмә буенча карары индивидуаль рәвештә кабул ителә.».

6. 4.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «4.3. Документларны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) бурычны түләтүгә өметсез бурыч дип тану һәм аны балансттан төшереп калдыру турында;

б) бурычны түләтүгә өметсез бурыч дип танудан баш тарту турында. Комиссия тарафыннан түләтүгә ышанычсыз бурычны танудан баш тарту турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) әлеге Кагыйдәләрнең 2.2 пунктында билгеләнгән нигезләрнең булмавы;

2) Комиссиягә әлеге Кагыйдәләрнең 3.1 - 3.6 пунктларында күрсәтелгән документларны тапшырмау, яисә аларны тулы күләмдә тапшырмау.

Әлеге карар Комиссия кисәтүләрен бетергәннән соң әлеге бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы мәсьәләне кабат карауга комачауламый.».

7. 4.8 пунктында «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының республика бюджетының исәп һәм хисаплылык бүлеге» сүзләрен «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының берләштерелгән, бюджет һәм бухгалтерлык хисаплылык бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

8. 4.10 пунктта «2.2.2, 2.2.4, 2.2.5, 2.2.6 пунктчаларында» сүзләрне «2.2.2., $2.2.2^1$, 2.2.4, 2.2.5, 2.2.6 пунктчаларындагы» сүзләргә алмаштырырга.

9. 4.11 пунктының икенче абзацында «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының республика бюджетының исәп һәм хисаплылык бүлеге» сүзләрен «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының берләштерелгән, бюджет һәм бухгалтерлык хисаплылыгы бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

10. 4.12 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының республика бюджетының исәп һәм хисаплылык бүлеге» сүзләрен «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының берләштерелгән, бюджет һәм бухгалтерлык хисаплылыгы бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.